**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422610 г.Лаишево,
ул. Первомайская, д.39
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Беренче май урамы, 39 нчы йорт,
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

---

**2026 елның 2 апреле** **38-РС номер**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2015 елның 27 апрелендәге «Лаеш муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы белешмәләрне Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге белешмәләрне массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен тәкъдим итү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында»гы 17-РС номерлы карарын үз көчен югалткан дип тану хакында**

Россия Федерациясе Президентының 2025 елның 31 декабрендәге «Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү һәм аларны үз көчен югалткан дип тану турында»гы 1009 номерлы Указының 4 нче пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2015 елның 27 апрелендәге «Лаеш муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы белешмәләрне Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге белешмәләрне массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен тәкъдим итү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында»гы 17-РС номерлы карарын;

2. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2016 елның 19 февралендәге «Район Советының 2015 елның 27 апрелендәге 17-РС номерлы «Лаеш муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы белешмәләрне Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге белешмәләрне массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен тәкъдим итү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында»гы 10-РС номерлы карарын.

3. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2022 елның 23 декабрендәге «Район Советының 2015 елның 27 апрелендәге 17-РС номерлы «Лаеш муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы белешмәләрне Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге белешмәләрне массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен тәкъдим итү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында»гы 109-РС номерлы карарын.

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылган (халыкка җиткерелгән) көненнән башлап үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе А.Ә. Нурмөхәммәтовка йөкләргә.

**Муниципаль район башлыгы –**
**Совет рәисе:** **И.Ф. Зарипов**